КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 май г.Казань № 572

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 гыйнвар, 49 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 июнь, 459 нчы, 2021 ел, 21 гыйнвар, 14 нче, 2021 ел, 26 апрель, 285 нче, 2022 ел, 15 август, 835 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «раслау» сүзе алдына «һәм әгъзалары санын» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе санын 140 кеше күләмендә;

бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы коллегиясе составында:

коллегия составыннан А.М.Миңголовны, Г.Р.Шакированы чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Зарипов Раушан Булат улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Хөсәенов Алмаз Әзһәр улын | Татарстан Республикасы спорт министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин